СОВЕТ ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

30.09.2016 | д. им. М. Вахитова | № 14-67

## Вахитов авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Вахитов авыл җирлеге Уставының 11 ст., Вахитов авыл җирлеге Советының 20.09. 2016 нчы елларда кабул ителгән 13-63нче номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары, Вахитов авыл җирлеге башлыгының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 ел 20 сентябреннән 5 нче номерлы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге  Советы
карар итте:

1. 2016 елның 20 ноябренә Вахитов авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«2017 елда Вахитов авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә  һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән килешәсезме:

- М.  Вахитов исемендәге авылда урнашкан зиратны төзекләндерү: 240 метр озынлыктагы койма, 1 керү төркеме ясау, хуҗалык блогын төзү, 1 данә 2х3 зурлыктагы блок, 15 данә иске агачларны кисү, 15 метр озынлыктагы керү юлына вак таш җәю;

- Ватан авылында 1 контейнер мәйданчгы төзү, 4 контейнерлар сатып алу;

Ташовка авылында 2 контейнер мәйданчыклары төзү, 8 контейнер  сатып алу;

Бакча-Сарай бистәсендә 4 контейнер мәйданчыгы төзү, 16 контейнер  сатып алу.

ӘЙЕ                                  ЮК".

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы   А.Ш. Залялетдинов